ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КҮҖӘКӘ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423734, Күҗәкә авылы,
Совет ур., 28 нче йорт.
Тел.3-44-48

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КУЗЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423734, село Кузякино,
ул. Советская,дом 28,
Тел. 3-44-48

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**11 ноябрь 2020 ел** **№1**

Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлегенең Күҗәкә,Адай,Иске Урьяды,Түбән Урьяды торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Күҗәкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Күҗәкә авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нче елның 16 ноябренә сәг.13.00 дә Адай авылында билгеләргә.

2. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нче елның 19 ноябренә Иске Урьяды,Түбән Урьяды авылларында сәг.10.00 дә билгеләргә

3. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нче елның 19 ноябренә Күҗәкә авылында сәг.13.00 дә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

1.Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

- җирләү урыннарын документаль рәсмиләштерү;

- зират коймасын төзекләндерү;

- зиарат йорты төзелеше.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;

- торак пунктлардагы урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләрне әзерләү һәм урнаштыру;

- җирлек торак пунктларында игъланнар тактасы ясау һәм аларны урнаштыру;

- һәйкәлләр территориясен төзекләндерү ;

- сулыктан су алу өчен янгын сүндерү машиналары өчен пирс төзү;

3.Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру:

- рәсми физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм массакүләм чараларны оештыру һәм уздыру;

4.Җирлек чикләрендә халыкны электр һәм су белән тәэмин итү:

- урамнарны яктырту, электр челтәрләрен карап тоту ;

- су челтәрләрен һәм чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын киртәләү һәм лицензияләү ,документаль рәсмиләштерү.

5. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юлларны һәм күперләрне ремонтлау , карап тоту (ПГС һәм вак таш җалу, грейдерлау, кардан чистарту).

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

3. 2020 елның 16 ноябрендә халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Адай авылы, Горький урамы, 2 нче йорт, 2020 елның 19 ноябрендә түбәндәге адрес буенча үткәрерә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Иске Урьяды авылы, Совет урамы, 23 нче йорт, 2020 елның 19 ноябрендә түбәндәге адрес буенча үткәрерә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Күҗәкә авылы , Совет урамы, 28 нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Күҗәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Н.Мусин

ОГРН 1021605559205
Совет
КУЗЯКИНСКОГО
сельского поселения
ИНН 1604001094